«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы

КАРАРЫ

2024 елның 30 июле № 92

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 14.11.2017 елгы 59 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 387 статьясындагы 2 пункты, шулай ук «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 36 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә дигән КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.1. 3 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"- су белән тәэмин итү һәм су агызу объектлары биләгән җир кишәрлекләренә, мәйданнар, урамнар, юллар, парклар, аллеялар, яшел утыртмалар, һәйкәлләр, бәйрәм чаралары уздыру урыннары, спорт объектлары һәм гомуми файдаланудагы башка объектлар биләгән гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата җирле үзидарә органнары, бюджет, казна учреждениеләре».

2. Әлеге карарның 3 статьясындагы 5 абзацы үз көчен 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Бортас авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Бортас авыл җирлеге Советы рәисе Р. С. Сәгдиев